ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БОЕРГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

«03» апрель 2024 ел Боерган авылы № 8

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге составына керүче Таулар авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 16 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Таулар авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Таулар авылында гражданнар җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Тукай муниципаль районы «Боерган авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Боерган авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Советының 2019 елның 29 октябрендәге 49/2 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге составына керүче Таулар авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 16 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Таулар авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 14 апрелендә 13.00 сәгатькә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге составына керүче Таулар авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«- торак пункт территориясен төзекләндерү (Туера авылының су күтәрү башнясына койма сатып алу һәм урнаштыру)»

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 16 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Таулар авылында гражданнар җыены карарына:

«- торак пункт территориясен төзекләндерү (Туера авылының су күтәрү башнясына койма сатып алу һәм урнаштыру)»

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Боерган авыл җирлеге, Таулар авылы, Алмаз ур., 52 нче йорт (Таулар авылы клубы бинасы).

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Боерган авыл җирлеге Башлыгы Г.Г. Минакова